| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>УЛЬЯНКОВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>УЛЬЯНКОВО АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

18.12.2023 Ульянково ав. № 84

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ульянково авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ульянково авыл җирлегенең муниципаль хезмәткәренә классы чиннар бирү турында тәкъдимнәр кертү тәртибе хакында нигезләмәне раслау турында» 2012 елның 26 сентябрендәге 28 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль норматив хокукый актларны «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 10 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2023елның 02 ноябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә китерү максатларында, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ульянково авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ульянково авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ульянково авыл җирлегенең муниципаль хезмәткәренә классы чиннар бирү турында тәкъдимнәр кертү тәртибе хакында нигезләмәне раслау турында» 2012 елның 26 сентябрендәге 28 номерлы карарына (алга таба текст буенча – Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- Нигезләмәнең 10 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;
- Нигезләмәнең 12 пунктында «квалификация имтиханы уздырганчы» сүзләрен «классы чин бирелгәнче» сүзләренә алмаштырырга;
-Нигезләмәнең 13 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: муниципаль хезмәткәргә классы чин бирү турында карар, әлеге Нигезләмәнең 7 пунктының икенче абзацында күрсәтелгән очраклардан тыш, җирле үзидарәнең органына яисә вазыйфаи затына, сыйныф чиннарын бирергә вәкаләтле вәкилгә кирәкле барлык документлар белән классы чин бирү турында тапшыру кертелгән көннән алып бер айдан да соңга калмыйча кабул ителергә тиеш;
- 15-20 пунктларны төшереп калдырырга;
- әлеге карарга 2нче кушымтаны төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru/) һәм Татарстан

Республикасы Кайбыч муниципаль районының Ульянково авыл җирлегенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге караның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Совет рәисе,
Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Ульянково авыл җирлеге башлыгы Ф.А.Сундурова